РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 51

2020 елның 29 июне

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Елантау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Елантау авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 27-83 номерлы карары белән расланган «Елантау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең график өлешенә үзгәрешләр кертергә:

16:30:120104:214 кадастр номерлы җир кишәрлегенең территориаль зонасын Р-1 рекреацион территорияләре зонасыннан Ж-1 шәхси торак йортлар төзү зонасына үзгәртергә (кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмаларында, Түбән Кама муниципаль районы һәм Елантау авыл җирлеге рәсми сайтларында бастырып чыгарырга.

3. «Елантау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, кертелгән үзгәрешләр белән, Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасына (РФ ТП ФДМС) һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.


4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләнә.


Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р.Метшин

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2020 елның 29 июнендә 51 номерлы
карарына кушымта

Елантау авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналаштыру картасыннан выкопировка




Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы урынбасары

Р.И.Хәбибуллин